***“Башкортостан Республикасы Агыйдел шәһәре шәһәр округы Үзәк китапханәсе” муниципаль автоном мәдәният учреждениесе***

# *Күп кырлы иҗат әһеле*




***Агыйдел - 2020 ел***

*Төзүче : Ә. Х. Әюпова*

*Күп кырлы иҗат әһеле Айгөл Әхмәтгалиева : магълүмати буклет/ Төз. Ә. Х. Әюпова. – Агыйдел : “БР Агыйдел шәһәре ШО  Үзәк китапханәсе” МАМУ, 2020*

…

**Ак гөлләрдән җан җылысы алып,**
**Йөрәкләргә саласы иде.**
**Ак чәчәкләр кебек ап-ак булып,**
**Саф күңелле каласы иде...**

**Айгөл Әхмәтгалиева**

**Сүз соңгы еллар татар әдәбиятында проза жанрында үзен өметле каләм иясе булып таныткан Чаллы шәһәрендә яшәп иҗат итүче танылган журналист, язучы Татарстан язучылар берлеге әгъзасы, «Мәйдан» журналының җаваплы секретаре һәм «Ислам нуры» дини-иҗтимагый гәзитенең баш мөхәррире Актаныш кызы Айгөл Әхмәтгалиева турында.**

**Айгөл Әхмәтгалиева иҗаты әдәбият сөючеләр тарафыннан зур кызыксыну белән өйрәнелә. Сәбәбе: ул язган темалар тормышчан булуы белән аерылып тора.**

**Айгөл Әхмәтгалиева шундый җылы, тирән эчтәлекле әсәрләре, шигырьләре белән генә түгел, ә «Ак чәчәкләр», «Синең күзләр» кебек киносценарийлар авторы буларак та халыкка таныш. Аның күп кенә шигырьләре көйгә салынган.**

**Тәкъдим ителгән мәгълүмати буклет яшь язучының донъя күргән әсәрләрен, аның тормош һәм иҗат юлын яктырта.**

**Буклет киң катлам укучыларга тәгаенләнгән.**



**Айгөл Габдулла кызы Әхмәтгалиева (паспорт буенча Муллагалиева) 1973 елның 27 ноябрендә Актаныш районы Иске Сәфәр авылында туа. Качкын авылында үсә, шунда урта мәктәп тәмамлый. 1990–1995 елларда Казан дәүләт университетының татар теле, әдәбияты, тарихы һәм көнчыгыш телләре факультетында укый.**

**Хезмәт юлын студент елларында Казанның 10 нчы гимназиясендә укытучы, «Мәгърифәт» газетасында корректор булып башлап җибәрә. Гаиләсе белән Чалы шәһәренә күченгәч, «Нур» «Мәйдан» журналының әдәбият бүлеген җитәкли. Аннан “Казан утлары” журналына бүлек редакторы булып күчә. Бүгенге көндә “Мәйдан” журналының җаваплы газетасында корреспондент, Чаллы дәүләт педагогия институтында укытучы булып эшли. 2001 елдан 2013 елга кадәр секретаре булып эшли. Тәүге язмалары мәктәп елларында ук матбугатта күренә башлый. Соңгы елларда хикәяләре, публицистик язмалары һәм юморескалары белән «Казан утлары», «Идел», «Сөембикә», «Мәйдан», «Тулпар», «Чаян» журналларында, “Мәдәни җомга” газеталарында актив катнаша.**


**2008 елда «Мәгариф» нәшриятында балалар өчен «Болытта җиләк үсә», 2011 елда Татарстан китап**

**нәшриятында өлкәннәр өчен повесть һәм хикәяләрне үз эченә алган «Синең өчен яшим» китабы, 2014 елда яшүсмерләр өчен “Мин гашыйк булдым” китабы басылып чыкты.**













**Айгөл Әхмәтгалиева 2011 елда Сажидә Сөләйманова исемендәге кызыксындыру премиясенә лаек була.**

**“Бәхет агачы” дигән драмасы “Яңа татар пьесасы 2012” конкурсында җиңеп чыга; 2013 елда республикакүләм уздырылган конкурста “Таллыкүлдә былбыл бар” повесте – икенче, “Зәңгәр күлмәк” дип аталган киносценарие – өченче урынны яулый.**




**2014 елда Айгөл 2014 елда Айгөл Әхмәтгалиевага, С. Гыйззәтуллина-Волжская турында роман язу өчен, Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлеге гранты бирелә. Шушы ук елда Мәхмүт Кашгарый**

исемендәге халыкара хикәяләр бәйгесендә “Капка” хикәясе белән катнашып, Татарстанда беренче, дәүләтара бәйгедә икенче урынны яулый. Автор үзе Чаллы шәһәрендә 2014 елның “Ел язучысы” дигән исемгә лаек була.


2015 елда Оренбург татар дәүләт драма театры А.Әхмәтгалиеваның – “Ул бит кичә иде” пьесасын сәхнәләштерде.

Әхмәтгалиевага, С. Гыйззәтуллина-Волжская турында роман язу өчен, Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлеге гранты бирелә. Шушы ук елда Мәхмүт Кашгарый исемендәге халыкара хикәяләр бәйгесендә “Капка” хикәясе белән катнашып, Татарстанда беренче, дәүләтара бәйгедә икенче урынны яулый. Автор үзе Чаллы шәһәрендә 2014 елның “Ел язучысы” дигән исемгә лаек була.

2015 елда Оренбург татар дәүләт драма театры А.Әхмәтгалиеваның – “Ул бит кичә иде” пьесасын сәхнәләштерде.

Хикәяләренең кайберләре рус теленә тәрҗемә ителгән. “Җиде ят” хикәясе исә, төрек теленә тәрҗемә ителеп, “Несе Oyku”, “Sessiz kuray” (Анкара) журнал-китапларында; балалар өчен язылган “Әби, Илнур һәм математика” хикәясе төрек телендәге “Altin Sincar” (“Алтын тиен”) җыентыгында урын алган. Хикәяләре мәктәп дәреслекләренә, “Яңа базар”, “Балачак энциклопедиясе” кебек җыентыкларга да кертелгән. А.Әхмәтгалиева – 2009 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.









## Библиография

**Синең өчен яшим : повесть, хикәяләр. - Казан : Тат. кит. нәшр., 2011. - 205, [2] с. : ил.**

**Таллыкүлдә былбыл бар:повестьлар, хикәяләр. – Казан: Тат. кит. нәшр., 2016. – 287 б.;**

**Сагынган чакларымда: пьесалар. – Казан: Идел-Пресс, 2018. - 328 б.;**

**Ак читек : повесть, хикәяләр,юморескалар, юлъязмалар. – Казан: Идел-Пресс, 2018. – 348 с.**

**Хәния: документаль бәян. – Чаллы: Ислам нуры, 2018. – 320 б.;**

**Туташ: роман. – Казан: Татар. кит. нәшр, 2019. – 527 б.;**

**Аллаярова Е. Журналист. Писатель. Драматург /Е. Аллаярова // Красное знамя. – 2020. – 5 марта (№26). – С. 5**

**Мәгълүмат чыганагы:**
https://sptatar.com/hm-tgalieva-ajg-l/

***Безнең адрес:***
***452920, Агыйдел шәһәре,***
***Беренче төзүчеләр ур., 7 А***
***Тел.: 8(34731) 27-3-56***
***E-mail: mukcbs55@mail.ru***
***Сайт: http://agidelbibl.ru /***
***В Контакте:***
***Центральная-Библиотека***
***Город-Агидель***

***Без эшлибез:***
***Үзәк китапханә***
***Эш сәгате: 10.00 – 19.00***
***Төшке аш: 13.00 – 14.00***
***Ял көне : шимбә***

***Агыйдел шәһәре тарихи-туган якны өйрәну музее***
***Эш сәгәте: 10.00 – 19.00***
***Төшке аш:13.00 – 19.00***
***Ял көне: шимбә***

***Балалар моделле китапханәсе***

***Эш сәгәте: 10.00 – 19.00***
***Төшке аш:13.00 – 19.00***
***Ял көне: шимбә***